# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«2000 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына өстәмәләр кертү хакында

1 статья. «2000 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 12) Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1 абзацына «предприятиеләрнең һәм оешмаларның» дигән сүзләрдән соң «авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре, Татарстан Республикасының агросәнәга комплексы предприятиеләреннән һәм оешмаларыннан тыш» дигән сүзләрне өстәргә;

5 абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең, Татарстан Республикасының агросәнәга комплексы предприятиеләренең һәм оешмаларының Татарстан Республикасының республика бюджеты алдындагы бурычларын реструктурлаштыруны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә үткәрергә. Реструктурлаштырылган бурычлар суммасына бюджет акчаларыннан файдаланган өчен процентлар исәпләнми».

2 статья. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 22 декабре
№ 561